**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БЕССОНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БЕССОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 51-2-18, факс 51-2-18

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**20 .10. 2022** **№2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең Югары Тархан торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Бессоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 9 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Югары Тархан авылы, Карл Маркс урамы, 14 нче йорт адресы буенча урнашкан Югары Тархан авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең Югары Тархан торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең Югары Тархан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына сроклы хезмәткә чакырылган күпбалалы гаиләләрдән тыш, махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, һәм аларның гаилә әгъзаларын (ата-аналар, хатыннар, балигъ булган балалар) һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Югары Тарханда Комсомольская, Зеленая, Совет урамнары буенча вак таш, төзелеш комы, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләрне түләү сметасы нигезендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау (авыл эчендәге юлларны ремонтлау) юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү;

- Югары Тархан торак пунктында урам яктырткычларын (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү) тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү?».

"КАРШЫ" "РИЗА"

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/ ).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Ю.А. Врясов**